ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**20.10.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2599**

2022 елга Зеленодольск муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге «Татарстан Республикасы балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 854 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елга түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымтада бирелгән норматив чыгымнарын (кушымта);
- балаларга сәнгать-эстетика юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын 0,5 күләмендә.

2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.В. Лулаковка йөкләргә.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　И.Р. Ганиев

Кушымта
Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына
20.10. 2021 ел, № 2599

**Зеленодольск муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территория ягыннан урнашуы | Норматив чыгымнар (бер укучыга елына, сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык укыту вакыты | дүрт еллык укыту вакыты | биш еллык укыту вакыты | җиде еллык укыту вакыты | иртә һөнәри ориентация |
| Музыка сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Музыка сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 25 592 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |